**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ БОГАДЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

423763, Иске Богадыа вылы, Үзәк ур.,
60нчыйорт.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОБУГАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

423763, село Старые Бугады,
ул. Центральная, дом 60.
Тел.:(85552)5-45-30; факс:5-45-30;
E-mail: sbuq-akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«22» ноябрь 2019 ел** **№ 31**

**Иске Богады авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 15.11.2019елгы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә Иске Богады авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Богады авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган яшәүчедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 1 төркем инвалидлардан кала, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан кала, 2020 елда үзара салымның бер тапкыр 500(Биш йөз) сум түләвен кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

* Күмү урыннарын карап тоту:
 -ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
 - күмү урыннарын документаль рәсмиләштерү;
* автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
 -Иске Богады авылы Үзәк, Яшьләр,М. Җәлил урамында, Иске Солтангол авылы Үзәк урамында, Югары Богады авылы Лесная урамында юлларны ремонтлау һәм карап тоту, (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)
* җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
 -торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
* урам утларын реконструкцияләү.
 -урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
* җирлек халкының күпләп ял итү өчен шартлар тудыру һәм ял итү урыннарын оештыру.

2. Актаныш муниципаль районы Иске Богады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында " Иске Богады авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Фаттахов.